МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.10.2021 г.Казань № 710

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 12 октяберендә 7977 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016 №420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691, 24.02.2021 №102, 21.05.2021 №331, 06.08.2021 №567 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 1 октябрендәге 710 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба - Регламент) расларга.»;

әлеге боерык белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.»;

1.4.1 пунктта «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.4.3 – 1.4.7 пунктларын өстәргә:

«1.4.3. Мөрәҗәгать итүче телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткән очракта Үзәк бүлекчәсенең консультация бирә торган белгече мөрәҗәгать итүчеләргә кызыксындырган сораулар буенча тулы һәм нәзакатьле (корректлы) формада мәгълүмат бирә.

Телефон мөрәҗәгатенә җавап бирү мөрәҗәгать итүче шалтыраткан органның атамасы, телефоннан мөрәҗәгатьне кабул иткән белгечнең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта) һәм вазыйфасын әйтүдән башланып китә.

Әгәр Үзәк бүлекчәсе белгече мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмый икән, телефон аша алынган мөрәҗәгать башка вазыйфаи затка адресланырга (күчерелергә) тиеш яисә мөрәҗәгать иткән затка кирәкле мәгълүматны алу мөмкинлеге булган телефон номеры турында хәбәр ителергә тиеш.

Җавапны әзерләү берникадәр вакыт таләп иткән очракта, ул мөрәҗәгать итүчегә эш итүнең түбәндәге вариантларын тәкъдим итә:

мөрәҗәгатьне язма рәвештә бәян итәргә;

консультацияләр өчен башка вакыт билгеләргә.

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтүнең стандарт процедуралары һәм шартлары кысаларыннан чыга торган һәм турыдан-туры яки читләтеп кабул ителә торган карарга йогынты ясый торган мәгълүматларны бирергә хокуклы түгел.

Телефон аша мәгълүмат җиткерү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

Мәгълүмат җиткерү гражданнарны кабул итү графигы нигезендә башкарыла.

1.4.4. Язмача мөрәҗәгать буенча Үзәк бүлекчәсенең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы белгече мөрәҗәгать итүчегә «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) күрсәтелгән мәсьәләләр буенча белешмәләрне язмача формада җентекләп аңлата.

1.4.5. Бердәм порталда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүне (функцияләрне гамәлгә ашыруны) тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә каралган белешмәләр урнаштырыла.

1.4.6. Үзәк бүлекчәсенең көтү залларында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар, шул исәптән мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа танышу өчен бирелә торган Регламент урнаштырыла.

1.4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны карау барышы хакында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинет аша, шулай ук, мөрәҗәгать

итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, Үзәк бүлекчәсеннән, телефон буенча, электрон почта аша алынырга мөмкин.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү (алга таба - компенсация).

2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы һәм шәһәр округындагы бүлекчәсе.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар тора (алга таба - компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

телефонга смс-хәбәр итеп.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар гариза һәм документлар теркәлгәннән соң 10 эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Компенсация биру (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларда күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләгәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыгракка түгел.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен биру (җибәрү) компенсация биру (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көннән алып бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, компенсация биру (бирүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

### 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) социаль түләүләр алу өчен федераль законнар нигезендә банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган счет реквизитларын күрсәтеп, компенсация биру турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

2) компенсация алу хокукын раслый торган документ;

2) күпфатирлы йортларда торак урыннарның милекчеләре өстәмә рәвештә аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документларның күчермәләрен дә тапшыра;

3) әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә эш урыныннан компенсация алу хокукы турында белешмә дә тапшыра;

4) әлеге Регламентның 1.2 пунктының 41 пунктчасында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән никахны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

5) 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарында каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән хезмәт ветераннары, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турындагы белешмәне тапшыра;

6) хезмәт ветераннары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләүдә субсидия-ташламалар бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләүдә субсидия-ташламалар бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәнең (алга таба – 126 номерлы нигезләмә) 1 пунктындагы өченче абзацында һәм 2 пунктының бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документларны өстәмә тапшыра.

2.5.2. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.3. Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать иткәндә, үзләренең шәхесен таныклый торган һәм мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклый торган документындагы белешмәләре исәпкә алыну язуы ИАБС расланган вакытта тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат тарафыннан бирелгән документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, шәхси

эшкуар тарафыннан бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

2.5.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.6. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Үзәк бүлекчәсенә яисә почта аша кәгазьдә;

Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша.

2.5.7. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.8. Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара бәйләнеш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре

турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында белешмәләр;

даими яшәү урыны буенча законнар нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданин белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында; инвалидлык билгеләнүе турында;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына компенсация билгеләү өчен);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

инвалидлык билгеләнүе турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә компенсация билгеләү өчен);

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен балага опека (попечительлек) билгеләнүе турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурыч булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен).

мөрәҗәгать итүченең торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурычлары булмавы турында;

мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслау турында;

Россия Федерациясенең башка субъектында социаль ярдәм чараларын алу/алмау турында;

тернәкләндерү турында;

паспортның чынлыгы турында.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге

Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.3. Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.1 пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

билгеләнгән таләпләрне бозып хезмәт күрсәтү турында гариза җибәрү бирү;

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны тулы булмаган рәвештә тапшыру;

тапшырылган документларның хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми

торган бозык урыннар булуы;

63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве;

63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар тапшыру;

гариза формасындагы, шул исәптән Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның проактив формасындагы кырларны тулылысынча (корректлы) тутырмау;

мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча карамаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрдә салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтүгә хокуклы булмавы;

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән булуы;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларның формасы һәм эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәве;

мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтү хокукына ия булган затлар категориясенә туры килмәве;

мөрәҗәгать итүченең торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурычлары булуы;

Татарстан Республикасы законнарында яки федераль законнарда билгеләнгән башка нигезләрдә, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, эшчеләр бистәләрендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшли һәм яши торган гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен раслау турында» 2005 елның 7 июнендәге 251 номерлы карары белән расланган Авыл

җирлегендә, эшчеләр бистәләрендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшли һәм яши торган гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибенең 15 пункты таләпләрен исәпкә алып, әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-40 пунктчаларында күрсәтелгән затларның социаль ярдәм чараларын алуы;

компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүченең төгәл булмаган белешмәләрне һәм документларны тапшыруы;

әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри башка түләүләр буенча компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән башлап 90 көн эчендә җайга салынмаган бурычлар булуы;

хезмәт ветеранының уртача айлык кереме 20 000 сумнан артып китүе;

хезмәт ветеранының төрләренең исемлеге 126 номерлы нигезләмәдә күрсәтелгән керемнәрнең булмавы;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

2.9.1. Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

2.10.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

2.11.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15

минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар исемлегенә карата таләпләр. Шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата да

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуал, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла, көтү заллары (бүлмәләре) мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителә, аларда әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук, тутыру үрнәкләре белән бергә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаларның формалары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә

**берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтү мөмкинлегенең булуы яки булмавы**

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе:

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarsta№.ru/ сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarsta№.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү гаризаларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.16.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында ИАБС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә җибәрелә. ИАБС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.16.3. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү

порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

кабул итү көннәре, вакыты һәм урыннары.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары. Аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) компенсация бирү (бирүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирү яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта урнаштыру.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Үзәк бүлекчәсе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Үзәк бүлекчәсенең вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү  һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта, электрон почта аша, техник мөмкинлек булганда, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) Үзәк бүлекчәсенә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлекчәсе белгече шәхсән, телефон, почта, электрон почта ярдәмендә, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, гариза бланкы бирә һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче компенсация билгеләү турында гаризаны Үзәк

бүлекчәсенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документларны (документларның күчермәләрен) теркәп тапшыра.

Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта буенча җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүченең электрон имзасы белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гаризаны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң гамәлгә ашырыла. Гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон

формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә өч ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Үзәк бүлекчәсенә Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.

3.3.2. Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Үзәк бүлечәсе белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Үзәк бүлекчәсе белгече:

Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан электрон гаризалар булу-булмавын көненә ике тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, язу тапшыра.

Документларны кабул итү һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, гаризаны теркәү һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә.

Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

3.3.1 һәм 3.3.2 пунктларында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә

гамәлгә ашырыла:

шәхсән кабул иткән очракта – гариза һәм документлар алынган көнне, әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрне исәпкә алып;

гариза һәм документлар Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгәндә яки почта, электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе көнне.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгәндә яки почта аша, электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән язу, документларны кабул итүдән баш тарту турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне вәкаләтле органнардан ала:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында белешмәләр (ялгыз пенсионерларга, хезмәт ветераннарына, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга, авыл җирлегендә яшәгән һәм эшләгән белгечләр исәбендәге пенсионерларга компенсация билгеләү өчен);

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

эшсезлек буенча барлык төр пособиеләрне һәм эшсезләргә башка түләүләрне түләү (түләмәү) турында;

мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

инвалидлык билгеләнүе турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган белешмәләр.

3.4.2. Компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне вәкаләтле органнардан сората:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында белешмәләр;

даими яшәү урыны буенча законнар нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданин белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында; инвалидлык билгеләнүе турында;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына компенсация билгеләү өчен);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

инвалидлык билгеләнүе турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә компенсация билгеләү өчен);

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен балага опека (попечительлек) билгеләнүе турында;

шәхси счетның иминият номеры турында:

салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурыч булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен).

мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслау турында;

Россия Федерациясенең башка субъектында социаль ярдәм чараларын алу/алмау турында;

тернәкләндерү турында;

паспортның чынлыгы турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5. Компенсация бирү (бирүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 3, 6 нчы кушымталар нигезендәге формалар буенча электрон рәвештә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар проектын яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе компенсация бирүү (бирүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап, Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проекты имзалау өчен җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар.

3.5.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (язмача формада шәхсән яисә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында Бердәм порталга, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталына шәхси кабинетка, телефонга смс-хәбәр җибәрү юлы белән) бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү.

3.5.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән затлар исәбендәге мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләр алынса яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече:

әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә компенсация бирү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм компенсация бирү турындагы карар проектларын Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалу өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар проекты, компенсация бирү турында карар проекты.

3.5.4.2. Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 3741 пунктчаларында күрсәтелгән затлар исәбендәге мөрәҗәгать итүченең компенсация бирү турында гариза тапшырылган көннән башлап 90 көн узгач Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары җайга салынмаган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече компенсация билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә. (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура компенсация бирү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: компенсация бирүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.4.3. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе 3.5.4.1 һәм 3.5.4.2 пунктларда күрсәтелгән карарларны карый, аларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалый һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турындагы карарны, компенсация бирү турындагы карарны, компенсация бирүдән баш тарту турындагы карарны Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура 3.5.4.1 һәм 3.5.4.2 пунктларда күрсәтелгән карарларның проектлары имзалау өчен җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар, компенсация бирү турында карар, компенсация бирүдән баш тарту турында карар.

3.5.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар, компенсация бирү турында карар, компенсация бирүдән баш тарту турында карарны бирү Регламентның 3.5.3 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.7. Техник хатаны төзәтү.

Техник хатаны төзәтү әлеге Регламентка 5 нче кушымтадагы форма буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турындагы документны яки мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документны (әгәр андый документлар бирелгән булса) теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.

3.7.1. Үзәк бүлекчәсе белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турындагы карар проектын яисә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында электрон рәвештәге карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын яисә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яисә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында электрон рәвештә Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карар.

3.8.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны яисә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карарны имзалый һәм аны Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яисә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар.

3.8.3. Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны яисә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул (язмача формада шәхсән яки почта адресы буенча, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында электрон почта адресы буенча) белән бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында яисә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында

үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү, үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.»;

Регламентка 1 нче кушымтада:

нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта»;

«торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләргә» сүзләрен «торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация бирергә» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

<< >>

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Кемгә: << >>

(фамилиясе, исеме, атасының исеме )

Элемтә өчен мәгълүмат: << >>

(Почта индексы һәм адрес)

КАРАР

торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь

ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында

№_______ Дата _______

(башкарма хакимият органының исеме)

____________ башлап, гр. ______________ тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар ____________ каралды.

БИРЕРГӘ/ҮЗГӘРЕШ КЕРТЕРГӘ _______, _______ башлап _______ башлап

әлеге категория буенча: _______

(Вәкаләтле хезмәткәрнең ФИА, вазыйфасы) Электрон имза сертификаты турында белешмәләр

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

____________ башлап, гр. ______________ тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар ____________ каралды.

БАШ ТАРТЫРГА

гр. ______________ __________ бирүдән

әлеге нигезләр буенча: _______

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча уңай нәтиҗә алу өчен гамәл кылу тәртибе турында аңлатмалар (конкрет киңәшләр күрсәтелә) _________.

Әлеге карарга _________ яки суд тәртибендә шикаять белдерелә ала.

_______ _______

(Вәкаләтле хезмәткәрнең ФИА, вазыйфасы) Электрон имза сертификаты турында белешмәләр»;

Регламентка 5 нче кушымтада:

нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта»;

«торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләүгә субсидия-ташлама

билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләрен «торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында» сүзләренә алмаштырырга;

6 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе
_______________________________________________
_________
_______________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар

№____________ «__» ______________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ___________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы _____________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу сәбәпле, торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне бурычларны түләгәнчегә кадәр, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артмаган чорга, туктатып торырга.

Бүлек җитәкчесе _______________ _________________
(Ф.И.А.) имза
Мөһер урыны

Бүлек белгече __________________ __________________
(Ф.И.А.) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:

Язмача ____________________________________________________
почта адресы буенча

sms-хәбәр итеп ________________________
телефон номеры

электрон почта буенча ________________________________
электрон почта адресы

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында яки Бердәм порталда шәхси кабинет аша

Бүлек белгече __________________ __________________
(Ф.И.А.) имза

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе ________________________________________
________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар

№___________ «__» _____________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салу сәбәпле, торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне «___» _______________ башлап яңартып җибәрегә.

Бүлек җитәкчесе _______________ ________________
(Ф.И.А.) имза
Мөһер урыны

Бүлек белгече __________________ __________________
(Ф.И.А.) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
Язмача ____________________________________________________
почта адресы буенча
sms-хәбәр итеп ________________________
телефон номеры
электрон почта буенча _________________________________
электрон почта адресы
Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында яки Бердәм порталда шәхси кабинет аша

Бүлек белгече ___________________ ___________________
(Ф.И.А.) имза»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтада:

нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта»;

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы булган вазыйфаи затлар турында белешмәләр».